ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 29 » декабрь 2018 ел №  1269

**2019 елга Арча муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2018 елның 10 сентябрендәге 767 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны балансланган кайнар ризык белән тәэмин итү нормаларының үтәлешен тәэмин итү максатларында Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

1.1 2019 елның 1 гыйнварыннан Арча муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүне һәр уку көненә 7 сум 40 тиен, ата-аналар түләве һәм мәктәп яны участогыннан керемнәр белән тәэмин итүне оештырырга.

1.2. 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган,ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар тәрбияләүче гаиләләрдә тәрбияләнүчеләрне кайнар аш белән тәэмин итүне җирле бюджет һәм мәктәп яны участогыннан керемнәр хисабына 22 сум 40 тиен күләмендә гамәлгә ашырырга.

1.3. Үз составында 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен кайнар ризык белән тәэмин итүне түләүсез оештыру рәвешендә социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында локаль норматив-хокукый акт кабул итәргә.

1.4. Тәэмин итәргә:

- укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллануны һәм исәпкә алуны контрольдә тоту, мәктәп ашлары ассортиментын мәктәп яны участокларында җитештерелгән продукция исәбенә баету эшен көчәйтергә;

- иртәнге һәм төшке ашның нормалары һәм сыйфатын исәпкә алып барырга һәм контрольдә тотарга;

- гомуми белем бирү учреждениеләренә продуктларның өзлексез китерелүен координацияләргә һәм контрольдә тотарга.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә (Ф.Р. Исмәгыйлев) 2019 елга Арча муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә гомуми белем бирү учреждениеләренең барлык укучылары өчен уку вакытында кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чаралары күрсәтүче органнар күрсәтелгән чараларны Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм ЕГИСО операторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИСО) куллану юлы белән бирү турында мәгълүматны җиткерүне тәэмин итәләр.

2018-2019 уку елына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 31.08.2018 ел, №737 карарын үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга http:pravo.tatarstan.ru) Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. И. Гарифҗновка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин